**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.03.2019 №291

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә инвестиция активлыгын арттыру, шулай ук Нурлат муниципаль районының муниципаль милеген нәтиҗәлерәк һәм рациональ файдалану максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милеге турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисенә йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 26 март, 291 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмә "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында" 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге178-ФЗ номерлы Федераль законнар, "Дәүләт сере турында" 1993 елның 21 июлендәге 5485-1 номерлы, "Татарстан Республикасы Дәүләт милке турында" 2005 елның 8 апрелендәге 65-ТРЗ номерлы, "Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре" 2007 ел, 22 нче август, 407 нче номерлы карары, "Татарстан Республикасының дәүләт милке Реестры турындагы нигезләмәне раслау турында" 2003 ел, 20 нче март, 150 нче номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 25 нче сентябрь, 1426 нчы номерлы боерыклары, 2008 елның 16 маендагы 327нче номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ачыла торган муниципаль милке турында мәгълүмат составын, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да шулай ук аны ачу тәртибен һәм вакытын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәндә аның белән кызыксынучы барлык кешеләрнең дә файдалана алуын тәэмин итү күздә тотыла.

1.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милеген исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә бирелә. Соратып алына торган мәгълүмат дәүләт серен тәшкил иткәндә мәгълүмат бирүдән баш тарту булырга мөмкин.

1.4.Юридик затларның мәнфәгатьләренә зыян китердәй мәгълүмат куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль

районының муниципаль милке Реестрында теркәлгән белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендә булган җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр күләмендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм "Интернет" челтәрендә сайтка урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Кызыксынган затларга язма мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да мәгълүмат бирелә.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге сайтка урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милек турында мәгълүмат түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматлар закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендә устав капиталы өлеше (акцияләр пакетлары) булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урыны, устав капиталында дәүләт өлеше);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар) исемлеге (атамасы, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, куллануны чикләү, өченче затларның хокуклары белән йөкләү);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) ;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

2.2. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында www.nurlat.tatarstan.ru адресы буенча ел саен 1 гыйнварга финанс елы тәмамланганнан соң дүрт айдан да соңга калмыйча басылып чыгарылырга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны ачу, хосусыйлаштыру турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милек реестрында теркәлгән аерым милек объектлары (алга таба –исәпләү объектлары) буенча мәгълүмат кызыксынган затларның мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милек реестрыннан хатлар яисә өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яисә аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көн вакыт эчендә «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милек реестрыннан өземтәләр:

- исәпкә алу объектлары хокукына ия булучыларга яки аларның законлы вәкилләренә;
- исәпкә алу объекты хуҗасы яки аның законлы вәкиленең ышаныч язуы булган физик һәм юридик затларга;
- Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына;
- җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт хакимияте органнарына;
- федераль дәүләт хакимияте органнарына, шул исәптән:

күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга, салым органнарына, судларга, хокук саклау органнарына, исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокуклылары белән бәйле эшләрне караучы суд приставларына, Федераль монополиягә каршы органга һәм Татарстан Республикасында аның территориаль органына бирелә.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга исәпкә алу объектларының Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милке Реестрында булуы турында мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Соратып алына торган мәгълүматны язмача бирүдән баш тарту мотивацияләнергә тиеш.

Соратып алынган мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр соратып алына;

мөрәҗәгатьнең эчтәлеге әлеге затны кызыксындырган мәгълүматны объектны берсүзсез билгеләргә мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милек реестрында мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән очракта.